СОВЕТ КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ — КАРАР

05.03.2020 — с. Кильдеево — 64-308

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»
карары проекты турында

Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставын гамәлдәге законнарга туры китерү максатында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына таянып һәм Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставы белән,

Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Советының Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Башлыгы тәкъдим иткән «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектын хупларга, аны беренче укылышта кабул итәргә һәм тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, эшне дәвам итәргә (1 кушымта).
2. Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставына кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр буенча кергән тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эшче төркем төзергә:
– эш төркеме рәисе, Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Башлыгы В.М.Бурдин;
– эш төркеме секретаре, Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Башкарма комитеты сәркатибе Лёвочкина Н.Н.;
Эшче төркем әгъзалары:
- Мукаева Роза Александровна – 3 номерлы Килди сайлау округы депутаты.
- Хваткова Елена Анатольевна – 6 номерлы Килди сайлау округы депутаты
3. Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставына

үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2 кушымта)

4. Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты буенча фикер алышуларда гражданнарның катнашу тәртибен расларга (3 кушымта)

5. Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр буенча халык алдында тыңлауларны 2020 елның 20 мартында 10.00 сәгатьтә Югары Ослан муниципаль районының Килди мәдәният йортында, Килди авылы Центральная урамы, 16 а йорты адресы буенча үткәрергә.

6. Эшче төркемгә Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Советына кергән тәкъдимнәрне гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Советына карауга кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Башлыгы В.М.Бурдин

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Советының
2020 елның 5 мартындагы
64-308 номерлы карарына
1 кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. Уставның 5 статьясындагы 1 пунктының 20 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелешне сүтү, үз белдеге белән корылган корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш объектларын үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына яки федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында Карар кабул итү»;

2. Уставның 33 статьясындагы 1 пунктының 24 пунктчасы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Уставның 50 статьясындагы 1 пунктының 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« 3) территориаль планлаштыру, җирдән һәм башка табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирәлекне саклау өлкәсендә:
- муниципаль норматив хокукый актлар проектлары буенча җәмәгать тыңлаулары, ачык тыңлаулар оештыра һәм үткәрә;
- халыкка экологик хәл турында хәбәр итә, тиешле органнарга предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның әйләнә-тирә мохиткә куркыныч тудыручы, табигатьтән файдалану турындагы законнарны бозучы гамәлләре турында хәбәр итә;
- Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә, үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү яки аны рөхсәт ителгән төзелеш, үзгәртеп кору, җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектларының чик параметрларына, территорияне планлаштыру документларына яки федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында Карар кабул итә»

4. Уставның 50 статьясындагы 1 пунктының 7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. төзекләндерү өлкәсендә:

- каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнаша;

- җирлек территориясен төзекләндерү буенча эшчәнлекне оештыра, җирлекнең төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тота;

- адресация объектларына адресларны бирә, адресларны үзгәртә, юкка чыгара, урам-юл челтәре элементларына (җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыннан тыш), җирлек чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәрен бирә, мондый атамаларны үзгәртә, юкка чыгара, дәүләт адреслы реестрында мәгълүматны урнаштыра»;

5. Уставның 50 статьясындагы 2 пунктының 13 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- җирлек территориясендә яшәүче хуҗаларсыз хайваннар белән эш итү эшчәнлеген башкара»;

6. 50 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

-«Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыру»;

7. Уставның 85 статьясындагы 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль финанс контроле бюджет хокук мөнәсәбәтләрен җайга сала торган хокукый актлар, җирле бюджеттан физик затларга бүтән түләүләр буенча гавами норматив йөкләмәләр бирә торган хокукый актлар нигезләмәләрен, шулай ук муниципаль контрактлар, шартнамәләр (килешүләр) шартларын үтәүне тәэмин итү максатларында гамәлгә ашырыла.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Башлыгы В.М.Бурдин

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Советының
2020 елның 5 мартындагы
64-308 номерлы карарына
2 кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИЛДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИЛДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА» КАРАРЫ ПРОЕКТЫНА КАРАТА ГРАЖДАННАР ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ТӘРТИБЕ.

1. Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Советының «Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр 2020 елның 19 мартына кадәр, Ф. И. О. һәм авторның яшәү урыны турында белешмәләрне күрсәтеп, язма рәвештә кертелә. Тәкъдимнәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 422585, Килди авылы, Үзәк урамы, 16 йорт, Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Советына эшче төркем сәркәтибе Левочкина Н. Н. авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан ителгән көннән башлап көн саен шимбә һәм якшәмбедән кала 8.00 дән 16.00 га кадәр. Белешмәләр өчен телефон: 8 (84379) 34-7-41.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Башлыгы В.М.Бурдин

Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Советының
2020 елның 5 мартындагы
64-308 номерлы карарына
3 кушымта

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИЛДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИЛДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДА» КАРАРЫ ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУДА ГРАЖДАННАРНЫҢ КАТНАШУ ТӘРТИБЕ

1. Халык тыңлауларында катнашу өчен гаризалар 422585, Килди авылы, Үзәк урамы, 16 йорт адресы буенча Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Советына Левочкина Н. Н. шәхсән яки почта буенча («Устав турында фикер алышу» дигән конвертта тамгасы белән) кабул ителә.
2. Халык алдында чыгыш ясау хокукы белән Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Советына язмача гариза биргән авыл халкы чыгыш ясый ал
3. Халык тыңлауларында чыгыш ясау хокукыннан башка барлык кызыксынучы җирлек халкы да булырга мөмкин.
4. Катнашучыларны теркәү халык тыңлаулары башланганчы 30 минут кала башлана.
5. Халык тыңлауларында чыгыш ясау хокукы белән катнашучылар гариза бирү вакытына карап чират тәртибендә үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырыла.
6. Халык тыңлауларында катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел.
7. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш тәмамланганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.
8. Халык тыңлауларында катнашучылар халык тыңлауларының барышына тыкшынырга, аларны өзәргә һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.
9. Халык тыңлауларында катнашучылар тарафыннан үткәрү тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгарып җибәрүне таләп итәргә хокуклы.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Башлыгы В.М.Бурдин